**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«30» октября 2019 г. № 647

**«2020 елга «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау» турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү учрежденияләренә норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» Башкарма комитеты муниципаль берәмлеге

КАРАР ИТӘ:

1. 2020 елга расларга:

«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты 0,5 күләмендә.

2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Әхмәтов Илнур Хатыйп улына йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башкарма комитеты җитәкчесе

«____________________________» ________________________

«Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең
______ ______________ 2019 ел
______ номерлы карары белән
Расланды

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (бер укучыга елына, сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | җиде еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Рәсем сәнгате | авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |